УДК 81-11

*Ф.К. Сәгъдиева*

# ХӘЗЕРГЕ КОГНИТИВ ЛИНГВИСТИКА

В настоящей статье проводится анализ теоретических разработок, направленных на решение новых задач и формирование инновационных подходов в рамках современной когнитивной лингвистики. Подчеркивается тенденция к активному взаимодействию когнитивной лингвистики с другими областями гуманитарного знания, что способствует экстенсивному развитию ее традиционных направлений, переосмыслению их в свете новых парадигм и обретению новаторских познаний. Новые знания опираются на фундаментальные концепции, которые уходят корнями в давнюю историю лингвистики, начиная с классических подходов к языку. Новизна исследования определяется тем, что в татарской науке о языке указанная тема почти не освещается, что создает трудности, связанные с пониманием новых задач современной татарской лингвистики. Теоретическая и практическая значимость работы определяется его релевантностью для дальнейшего развития татарского языкознания. В настоящее время учеными проявляется большой интерес к проблемам глубинных закономерностей языкового механизма. В этой связи на передний план выдвигаются вопросы, связанные с методикой и методологией. В общей сложности все эти вопросы относятся к теории языка и касаются сущности языкового знака. И всем этим занимается когнитивистика. В языкознании под когнитивистикой принято понимать область взаимоотношения языка, мышления и сознания.

**Ключевые слова:** когнитивная лингвистика, когнитивная семантика

This article analyzes theoretical developments aimed at addressing new challenges and developing innovative approaches within contemporary cognitive linguistics. It emphasizes the trend toward active interaction between cognitive linguistics and other fields of the humanities, which facilitates the extensive development of its traditional fields, their rethinking in light of new paradigms, and the acquisition of innovative insights. The fundamental ideas fueling this new knowledge are rooted in the deep layers of the history of linguistic thought, originating in classical linguistics. The novelty of this study stems from the fact that this topic has received scant attention in Tatar linguistics, creating difficulties in understanding the new challenges facing contemporary Tatar linguistics. The theoretical and practical significance of this work is determined by its relevance to the further development of Tatar linguistics. Scholars are currently showing great interest in understanding the underlying principles of linguistic mechanisms. In this regard, questions related to methodology and methodologies come to the fore. All of these questions relate to the theory of language and concern the essence of the linguistic sign. This is all the subject of cognitive science. In linguistics, cognitive science is commonly understood as the field of interaction between language, thought, and consciousness.

**Keywords:** cognitive linguistics, cognitive semantics

Тел мәсьәләсенә мөнәсәбәтле заманча тикшеренүләрдә дөньяны тел чаралары ярдәмендә модельләштерүнең, тел белеме мәсьәләләре кысаларыннан чыгып, гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләренә үтеп кереп, дисциплинара методологик механизм дәрәҗәсендә каралганлыгы билгеләп үтелә [14].

Бүгенге фәнни парадигма кысаларында дөньяны тел чаралары ярдәмендә модельләштерү үзенчәлекләренә мөрәҗәгать итү билгеле бер мәдәнияттә формалашкан милли дөнья сурәтен, дөньяның үзенчәлекле образларын өйрәнүгә ярдәм итә [15].

Когнитив лингвистиканың өйрәнү объекты булып кеше акылы, фикерләве һәм алар белән бәйле булган менталь процесслар тора. Когнитив лингвистика – ул белем һәм танып белү, кешенең эшчәнлеге барышында дөньяны кабул итүе турындагы фән [12: 6].

Когнитив фән позициясеннән караганда, кеше мәгълүмат эшкәртүче система буларак өйрәнелә, ә аның эшчәнлеге мәгълүматны алу, эшкәртү, саклау һәм рациональ куллану өчен аны кабат торгызу буларак тасвирлана. Аның иң мөһим принципларыннан берсе – кешене актив рәвештә мәгълүматны кабул итүче һәм җитештерүче субъект итеп тану. Кеше үзенең фикерләү эшчәнлегендә билгеле бер «схемалар, программалар, планнар, стратегияләр»гә нигезләнеп эш итә [12: 7].

Бу очракта тел белемне теркәү, саклау, эшкәртү һәм тапшыруның төп чарасы булып тора. Шунлыктан когнитив фән тел белеменә игътибар итә дә. Нәтиҗәдә психология, неврология, фәлсәфә, ясалма интеллектны модельләштерү, антропология һәм башка фәннәр белән тыгыз бәйләнгән яңа фән – когнитив лингвистика барлыкка килгән. Аңарда белем категориясе, белем төрләре һәм аларны күрсәтү ысуллары (бу очракта заманча компьютерлар белән автоматик эшкәртүгә юнәлдерелгән ысуллар күздә тотыла) мәсьәләсе төп категория булып тора [12: 8].

Когнитив лингвистика телне танып белү субсистемаларының, белемнең менталь системаларының берсе буларак өйрәнә. Тел белгечләре аны телне гомуми когнитив механизм, корал буларак караган лингвистик юнәлеш итеп аңлаталар – ул билгеләр системасы, ул мәгълүматны чагылдыруда (кодлаштыруда) һәм трансформацияләүдә катнаша [8: 53]. Телдә кешенең танып белү эшчәнлеге нәтиҗәләре беркетелә. Когнитив лингвистика кысаларында телне кешенең интеллектуаль эшчәнлек формаларыннан аерым карап булмый.

Бу өлкәгә караган мәсьәләләр һәм төшенчәләрне өйрәнү белән үз вакытында алман галиме В. фон Гумбольдт шөгыльләнгән. Аның фикеренчә, нинди генә предмет турында сүз бармасын, аны һәрвакыт кеше белән, ягъни аның бөтен интеллектуаль һәм әхлакый бөтенлеге белән бәйләп була [7: 6]. Галим телне өзлексез иҗади эшчәнлек итеп караган: «Тел – эшчәнлек нәтиҗәсе (ergon) түгел, ә үзе үк эшчәнлек (energeia). <...> Тел – ул рухның даими яңартылучы хезмәте, ул авыз белән чыгарылган авазны фикерне белдерү өчен яраклы итүгә юнәлтелгән» [7: 70]. В. фон Гумбольдт тарафыннан тел эшчәнлеге кеше эшчәнлегенең барлык башка төрләренең нигезе итеп аңлатыла.

Шулай итеп, ул антропоцентризмны методологик принцип буларак күрсәтүче, тел белән фикерләүне бәйләнештә карап, телне эшчәнлек, иҗади эшчәнлек нәтиҗәсе буларак билгеләгән динамик концепция тәкъдим итә. В. фон Гумбольдт телнең когнитив табигатен һәм функциясен түбәндәгечә аңлата: кешенең аралашуга эчке ихтыяҗы

телнең барлыкка килүенә ярдәм иткән. Бу ихтыяҗ кешенең үзенең табигатенә салынган. Ул аның дөньяга карашын формалаштыру, рухиныклыгын арттыру өчен кирәк. Моңа кеше үзенең фикерләвен иҗтимагый фикер белән бәйләп үстергәндә генә ирешә ала [6: 51]. Бу фикер – сүзне психолингвистик яссылыкта карау теориясендәге төп фикерләрнең берсе: сүз артында торган төп мәгънә индивидның психик эшчәнлеге закончалыклары кысаларында формалаша, әмма ул җәмгыять калыплашкан закончалыкларга нигезләнә [9].

Казан галиме И.А. Бодуэн де Куртенэ хезмәтләрендә дә алда әйтелгәннәргә охшаш фикерләрне табарга мөмкин. Хәзерге тел белгечләре дә галимнең әлеге тәгълиматын анализлаганда шуны билгеләп үтәләр: рус когнитив лингвистикасы И.А. Бодуэн де Куртенэ хезмәтләрендә үк формалаша башлаган, ул телгә белем призмасы аша карауны, ассоциатив психологизмны, герменевтик һәм эшчәнлекле алымнарны үз эченә алган. Аның фикеренчә, тел – ул үзе белем, тел белеме, ул интуитив, кешенең табигатенә салынган, тәҗрибәдән, күзәтүчәнлектән тупланган белем, теоретик һәм фәнни белемнәр белән бергә яши [3: 94]. Башта галим телне – психик күренеш, ул кешеләрнең җаннарында гына яши һәм бары тик шәхси тел генә чынбарлыкка ия, ә гомуми милли тел – ул уйдырма, фәнни абстракция дип билгели, ә соңрак ул телнең социаль ягына да басым ясый [3: 131]. Шул вакытта ук И.А. Бодуэн де Куртенэ телнең күп аспектлы булуына игътибар итә. Ул тел функцияләрен аерым-аерым карауны кирәк дип тапмый. Галим өчен тел – ул психик һәм шул ук вакытта иҗтимагый күренеш тә. Аның фикеренчә, тел – дөньяга үзенчәлекле караш [3: 8], чөнки ул шәхеснең һәм җәмгыятьнең фикерләрен һәм кәеф-халәтен дә үз эченә ала [13]. Когнитив фәннең үзәгендә кеше, аның фикерләве. Нәкъ менә кеше дөньяда һәм телдә төп рольне башкаручы булып тора. Шулай итеп, кеше акылының ничек корылганлыгы һәм аның телдә ничек чагылышы турындагы фән – ул когнитив фән була.

Когнитивистика мәсьәләләре татар мәгърифәтчеләре хезмәтләрендә дә урын ала. К. Насыйри үзенең хезмәтләрендә кеше шәхесен формалаштыруга кагылышлы киң спектрдагы проблемаларны күтәрә. Ул балаларны тәрбияләүдә мөһим бурычларның берсе – аларның дөрес физик үсешен тәэмин итү, шулай ук акылын, хәтерен һәм фикерләү сәләтләрен үстерү, әйләнә-тирә чынбарлык турында белемнәр белән баету һәм үз-үзен таныргa ярдәм итү дип санаган.

М. Корбангалиев балаларга телләрне чагыштырып өйрәтү кирәклеге турында туган телне башка тел белән чагыштыру, чагыштыручының тел күзаллавын һәм тел турындагы фикерләү сәләтен киңәйтә дип яза [1: 47–48].

Галимнәр әйтүенчә, телдә кешенең танып-белү эшчәнлеге барышында алган барлык мәгълүмат һәм тәҗрибә эшкәртелә һәм үзенең чагылышын таба. Кешелек тәҗрибәсен, дөнья турындагы белемнәрне структуралаштыру һәм ныгыту, индивидуаль аңда белемне тәкъдим итү һәм саклау формасы булып тел аңы һәм гомумән аның фрагменты булган сүз мәгънәсе тора. Е.С. Кубрякова фикеренчә, когнитив

процесслар тел белән бәйле һәм «телгә караган» процесслар буларак карала [11]. В.А. Маслова карашы буенча, когнитив лингвистиканың максаты – «дөньяны кабул итү, категорияләштерү, классификацияләү һәм аңлау процессларының ничек башкарылуын, белемнәрнең ничек тупланууын, эшчәнлек һәм мәгълүматның төрле төрләрен нинди системалар тәэмин итүен аңлау» [12: 12].

Когнитив лингвистикада алдынгы юнәлешләрнең берсе – когнитив семантика [5]. Лингвистикада когнитив якын килүнең иң ачык чагылышы – когнитив семантикада. Галимнәрнең когнитив семантикага карата булган кызыксынуын берничә сәбәп белән аңлатып була. Телнең табигый халәтендә кеше акылының дөньяны үзләштерү нәтиҗәсе чагыла. Тел берәмлекләренең мәгънәләрен өйрәнү дөньяның концептуаль картинасын билгеләргә мөмкинлек бирә. Классик семантикада фикерләү категорияләре һәм чынбарлык категорияләре белән бәйле мәгънәне өйрәнүгә кагылышлы белемнәр тупланган. Хәзерге лингвистикада мәгънә белән төшенчә, мәгънә белән әһәмият, мәгънә белән функция арасындагы бәйләнеш проблемалары төрле яклап карала.

Лексик мәгънә структурасының төрле тасвирламалары бар, аларда макро- һәм микрокомпонентлар аерып чыгарыла. Шулай ук когнитив семантиканы өйрәнүдә төп объектларның берсе булып мәгънәне өйрәнү тора. Хәзерге карашларга нигезләнгәндә, «билгенең әһәмияте турындагы мәсьәлә аның концептуаль яки когнитив “түбә” астында каралуы, билгедән дөнья турындагы мәгълүматларның гомуми агымыннан нинди информация чыгуы турындагы мәсьәлә буларак формалаштырылырга тиеш», – дип яза Е.С. Кубрякова [8: 23].

Хезмәттә мәгънә «билге эченә кергән концепт» дип билгеләнә. Мәгънәдә дөнья сурәте тел аша чагылыш таба. Когнитив лингвистика вәкилләре когнитив семантиканы концептуальләштерү һәм категорияләштерү теориясе, кешенең әйләнә-тирә дөньяны ничек кабул итүе, аңлавы һәм аның танып белү тәҗрибәсе тел чараларындагы мәгънәләрдә ничек тормышка ашырылуы теориясе дип атыйлар.

Шул уңайдан фән алдына актуаль лингвистик объектларны үзләштерү буенча яңа бурычлар куела. Мәкаләдә когнитив семантикага караган үзәк мәсьәләләр билгеләнде:

1) кеше аңында дөньяны категорияләштерү ысулларының берсе буларак прототиплар теориясе;

2) мәгънәне сүзлек рәвешендә күрсәтү проблемасы һәм семантик метател төзү;

3) кешенең танып белү механизмы һәм кеше фикерләвен оештыру турында мәгълүмат чыганагы буларак метафора теориясе;

4) полисемия проблемасы (бер мәгънәдән икенчесенә күчүнең типларын яисә ысулларын тасвирлау);

5) композицион семантика (мәгънәләре артында комплекслы, полипропозитив когнитив (төп ситуациянең фикердәге образы) торган тел берәмлекләре семантикасы);

6) когнитив ракурста сүз төркемнәре.

Шулай итеп, когнитив лингвистика хәзерге тел белемендә яңа юнәлеш буларак карала. Фән буларак ул телнең кеше тәҗрибәсен оештырудагы, дөньяны концептуальләштерүдәге, категорияләштерүдәге, мәгълүматны нығытудагы, аны саклаудагы, хәтердән чыгарудагы (извлечении из памяти) һ. б. рольләрен өйрәнә.

**Әдәбият**

1. *Асадуллин А.Ш.* Заглядывая в прошлое методической науки. Казань: Мастер Лайн, 2001. 256 с.

2. *Бодуэн де Куртенэ И.А.* Язык и языки // Избранные труды по общему языкознанию. М.: Изд-во АН СССР, 1963. Т. 2. С. 67–95.

3. *Бодуэн де Куртенэ И.А.* Значение языка как предмета изучения // Избранные труды по общему языкознанию. М.: Изд-во АН СССР, 1963. Т. 2. С. 129–138.

4. *Бодуэн де Куртенэ И.А.* Некоторые из общих положений (Из «Словаря» С.А. Венгерова) // Избранные работы по общему языкознанию. М.: Изд-во АН СССР, 1963. Т. 1. С. 348–350.

5. *Болдырев Н.Н.* Когнитивные схемы языковой интерпретации // Вопросы когнитивной лингвистики. 2016. № 4. С. 10–20.

6. *Гумбольдт В.* Язык и философия культуры. М.: Прогресс, 1985. 451 с.

7. *Гумбольдт В.* Избранные труды по языкознанию / пер. с нем. яз. под ред. и с предисл. Г.В. Рамишвили. 2-е изд. М.: Прогресс, 2000. 396 с.

8. *Демьянков В.З., Кубрякова Е.С.* Краткий словарь когнитивных терминов / под общ. ред. Е.С. Кубряковой. М.: Изд-во МГУ, 1996. 245 с.

9. *Залевская А.А.* Введение в психолингвистику. М.: Российский гос. гуманитарный ун-т. 2007. 360 с.

10. *Кубрякова Е.С.* Возвращаясь к определению знака // Вопросы языкознания. 1993. № 4. С. 18–28.

11. *Кубрякова Е.С.* Об установках когнитивной науки и актуальных проблемах когнитивной лингвистики // Вопросы когнитивной лингвистики. 2004. № 1. С. 6–17.

12. *Маслова В.А.* Введение в когнитивную лингвистику: учеб. пособие. М.: Флинта: Наука, 2004. 296 с.

13. *Маслова В.А.* Учение И.А. Бодуэна де Куртенэ о природе языка и его сущности // Филология и культура. 2015. № 2. С. 76–79.

14. *Маслова В.А.* Диалог как методология поэтического текста // Основы мироосознания в когнитивном аспекте. СПб., 2023. С. 3–6.

15. *Сагдеева Ф.К.* Проблемные поля когнитивной лингвистики (на материале татарского языка). Казань: РИЦ «Школа», 2025. 206 с.

***Сәгъдиева Фәүзия Кәбир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Сагдеева Фаузия Кабировна,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник*
*отдела общей лингвистики Института языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*fauzija.sagdeewa@yndex.ru*